# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# «МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

«15»март 2022 ел № 21/2

**Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 өлеше һәм 5 статьясы 1.3 өлеше,Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ**:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен район Башкарма комитетына тапшыру турында мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

- салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү объектларына концессион килешү төзүгә уртак конкурс үткәрүне оештыру;
- муниципаль милекне арендага бирү һәм милекче кушуы буенча концессиягә тапшыруны оештыру.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

3. Әлеге карарны Мәләкәс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ю.П.Васильев